ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

22 10 2024 г. № 1067

«Авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарны торак төзелешенә (сатып алуга) социаль түләүләрне файдаланып торак шартларын яхшыртырга теләк белдергән катнашучылар исемлегенә, шулай ук торак урынны наем шартнамәсе буенча бирелә торган авыл территорияләрендә торак төзү (сатып алу) гамәлләрендә катнашучылар исемлегенә кертү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 27 февралендәге 152 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставының 75 статьясы, Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитеты карар итә:

1. «Авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарны торак төзелешенә (сатып алуга) социаль түләүләрдән файдаланып торак шартларын яхшыртырга теләк белдергән катнашучылар исемлегенә, шулай ук торак урынны наем шартнамәсе буенча бирелә торган авыл территорияләрендә торак төзү (сатып алу) гамәлләрендә катнашучылар исемлегенә кертү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 27 февралендәге 152 номерлы карарына (алга таба - карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта «Хаҗиев Р.А.» сүзләрен «Парамонов М.Г.» сүзләренә алмаштырырга.»;

карар кушымтасында:

3.2 пунктындагы 3.2.1 пунктчасының дүртенче абзацында, 3.3.3 пунктындагы 3.3.1 пунктындагы 3.3.3.1 пунктының икенче абзацында, 3.4 пунктындагы 3.4.1 пунктындагы 3.5.1 пунктчасының икенче абзацында, 3.6.6 пунктындагы 3.6.1 пунктчасының икенче абзацында «шәһәр төзелеше сәясәте идарәсенең баш белгече» сүзләрен «торак сәясәте бүлегенең баш белгече» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Җитәкче Р.Ф. Булатов